**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әсәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әсәй авылы № 23-10 17 март 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 116-63 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (2015 елның 18 августындагы 145-78нче номерлы, 2015 елның 28 октябрендәге 14-3нче номерлы, 2018 елның 18 апрелендәге 12нче номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 31нче номерлы, 2018 елның 18 декабрендәге 37нче номерлы, 2019 елның 4 июлендә 18нче номерлы карарлар редакциясендә)

"Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 23 ноябрендәге 374-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Әсәй авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы ___авыл җирлеге Советының 2014 елның 116-63 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (2015 елның 18 августындагы 145-78нче номерлы, 2015 елның 28 октябрендәге 14-3нче номерлы, 2018 елның 18 апрелендәге 12нче номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 31нче номерлы, 2018 елның 18 декабрендәге 37нче номерлы, 2019 елның 4 июлендә 18нче номерлы карарлар редакциясендә) 3.2 пунктындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче салым органына салым ташламасы бирү турында гариза бирмәгән яисә салым ташламасын куллanудан баш тарту турында хәбәр итмәгән очракта, салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексы һәм салым түләүченең салым ташламасына хокукы барлыкка килгән салым чорыннан башлап салым органы тарафыннан алынган белешмәләр нигезендә бирелә."

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай

муниципаль районының Интернет- мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырырга: http://aznakayevo.tatar.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис З.Ә. Идрисов.